ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

« 10 » сентябрь 2017 ел №1021

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 23 сентябрендәге «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында»гы 1218 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына Адреслылык принцибын үтәү һәм мохтаҗлык критерийларын куллану бурычларыннан чыгып, социаль ярдәм күрсәтү чараларын исәпкә алу һәм камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында " 29.12.2015 ел, №388 – ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 23 сентябрендәге «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында»гы 1218 номерлы карарына түбәндәге өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына социаль ярдәм чараларын Адреслылык принцибын үтәү һәм мохтаҗлык критерийларын куллану бурычыннан чыгып бирү һәм камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 29.12.2015 ел, №388 – ФЗ Федераль закон нигезендә социаль ярдәм чараларын күрсәтүче органнар күрсәтелгән социаль ярдәм чараларын социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан файдалану юлы белән бирү турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәләр (алга таба-социаль ярдәм күрсәтү – ЕГИСО) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә, ЕГИСО операторы билгеләгән форматларга туры китереп.»

1.2. түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга. http:pravo.tatarstan.ru) Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.»

1.3. 5 пунктны 7 пункт дип санарга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче И.Ә.Галимуллин